ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.02.2024 ел Баулы шәһәре №12

“2024 елда Баулы муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны бушлай туклану белән тәэмин итү турында” 2023 елның 6 октябрендәге 188 номерлы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

“Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифралы платформа” дәүләт мәгълүмат системасы турында” 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Карарына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. “2024 елда Баулы муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны бушлай туклану белән тәэмин итү турында” 2023 елның 6 октябрендәге 188 номерлы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге МКУ начальнигы Ганиева Д.З. «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» (алга таба – БҮП) дәүләт мәгълүмат системасында социаль ярдәм чаралары турында мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм БҮП операторы билгеләгән форматларга ярашлы рәвештә җибәрүне (урнаштыруны) тәэмин итәргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) чыгарырга .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров